РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай
районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

"24" октябрь 2022ел №39

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендәге 84-48нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектны әзерләү хакында (2016 елның 30 ноябрендәге 45нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 13нче, 2020 елның 10 мартындагы 35нче, 2021 елның 11 августындагы 31-17нче номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетының җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советы карар итә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 февралендәге 84-48нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (2016 елның 30 ноябрендәге 45нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 13нче, 2020 елның 10 мартындагы 35нче, 2021 елның 11 августындагы 31-17нче номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә керешергә

1.1. 25 статьяны «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 12 пунктына туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Әсәй  авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча  урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.//

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Ә. Идрисов.

Азнакай муниципаль районы  Әсәй авыл җирлеге
башкарма комитет карарына
1 нче кушымта
№39  24.10.2022 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында муниципаль берәмлек проектын әзерләү эшләрен башкаруның якынча сроклары**

| **N** | **«Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен уздыру тәртибе** | **Эшләрне башкару вакыты** |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2022 елның IV кварталы |
| 2.<br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2022 елның IV кварталы |
| 3.<br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районы _____ авыл җирлеге башлыгына Азнакай муниципаль районының «______ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) авыл җирлеге Советына раслау яисә кире кагу өчен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын җибәрү турында карар кабул итү өчен, аны кабат тәкъдим итү көнен күрсәтеп, эшләп бетерерү турында карар кабул итү өчен юлларга. | 2022 елның IV кварталы |